Физкультура - сәламәтләндерү, спорт
һәм тренировка чараларына чыгымнар
нормаларын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 18 мартындагы 160 номерлы «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының физкультура-савыктыру һәм спорт чараларының календарь планына кертелгән физкультура-савыктыру, спорт һәм тренировка чараларын үткәрүгә чыгымнар нормаларын раслау турында» карары белән җитәкчелек иткәндә, физкультура-савыктыру, спорт һәм тренировка чараларында катнашуга чыгымнар нормаларын тәртипкә салу максатларында Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТТЕ:

1. Кушымта итеп бирелә торган түбәндәгеләрне расларга:

- физкультура-сәламәтләндерү, спорт һәм тренировка чараларында катнашканда спортчыларны, тренерларны һәм белгечләрне тукландыруга чыгымнар нормаларын (1 нче кушымта);

- спортчыларны, тренерларны һәм физкультура-сәламәтләндерү, спорт һәм тренировка чараларында катнашучыларны яшәү белән тәэмин итү чыгымнары нормаларын (2 нче кушымта);

- район спорт чараларын үткәргәндә истәлекле бүләкләр алу өчен чыгымнар нормалары (3 нче кушымта).

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслау җирле бюджет акчалары исәбеннән башкарыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Җәләлов А.Ф. йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ш.А. Алиуллов

Вилданов Р. Р., (84375) 2-20-51

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль
районы Башкарма комитетының
2015 елның "__"__________
____ номерлы карарына 1 нче
кушымта

Физкультура-сәламәтләндерү, спорт һәм тренировка чараларында катнашканда спортчыларны, тренерларны һәм белгечләрне тукландыруга
ЧЫГЫМНАР НОРМАЛАРЫ

| Спорт чараларының исеме | Көнгә бер кешегә чыгымнар нормасы, сум |
|---|---|
| Массакүләм физкультура-спорт ярышлары һәм чаралар | 300 |
| Татарстан Республикасы чемпионатлары, беренчелекләре, кубоклары һәм аларга әзерләнү чаралары (спартакиадалар, универсиадалар) | 350 |
| Бөтенроссия ярышлары һәм аларга әзерләнү чаралары | 600 |

Башкарма комитетының
эшләр идарәчесе: Д.Р. Сабирзянова

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Башкарма комитетының 2015
елның "__"__________ ____
номерлы карарына 2 нче
кушымта

Спортчыларны, тренерларны һәм физкультура-сәламәтләндерү, спорт һәм тренировка чараларында катнашучыларны яшәү белән тәэмин итү
ЧЫГЫМНАРЫ НОРМАЛАРЫ

| Яшәү өчен торак пунктлар категорияләре исеме | Бер кеше өчен көн бәясе - сум |
|---|---|
| Россия Федерациясе территориясендә шәһәрләр һәм торак пунктлар | 750 - 920 |
| Татарстан Республикасы территориясендә шәһәрләр һәм торак пунктлар | 350 - 700 |

Башкарма комитетының
эшләр идарәчесе: Д.Р. Сабирзянова

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Башкарма комитетының
2015 елның "__"_______
номерлы карарына 3 нче
кушымта

Район спорт чараларын үткәргәндә истәлекле бүләкләр алу өчен
ЧЫГЫМНАР НОРМАЛАРЫ

| Спорт чараларының исеме | Истәлекле бүләкләр бәясе, сум | |
|---|---|---|
| | Команда ярышлары | Шәхси ярышлар |
| Татарстан Республикасы чемпионатлары, беренчелекләре һәм кубоклары финаллары, шулай ук физкультура-массакүләм спорт ярышлары<br>I урын<br>II урын<br>III урын | 1500кә кадәр<br>1300гә кадәр<br>1100гә кадәр | 1200гә кадәр<br>1000гә кадәр<br>800 гә кадәр |

Башкарма комитетының
эшләр идарәчесе: Д. Р. Сабирзянова